| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2017 ел, 21 март | № 164 |

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 980 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 24 декабрь, 967 нче, 2015 ел, 30 декабрь, 1021 нче, 2016 ел, 1 март, 125 нче, 2016 ел, 3 июнь 369 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа паспортында:

«Дәүләт заказчысы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы»; |

Программаның 4 бүлегендәге беренче, сигезенче, тугызынчы абзацларда «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков